| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ**<br>**Старосляковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Иске Эсләк авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.11.2019 Иске Эсләк авылы № 55-5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының 31.01.2019 № 48-1 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы нигезендә, муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының 31.01.2019 № 48-1 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 11.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

«11.2. Граждан муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, Рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлык яисә үзлекләре (ата-аналары, хатыннары, балалары, абыйлары, апалары, ире яки хатынынң ата-аналары, абыйлары, апалары, балалары) очрагында муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларын били алмый.»

**1.2. 15нче бүлекнең 15.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«15.14. Әлеге бүлекнең 15.13 пунктчасы нигезендә башкарылган тикшерү нәтиҗәсендә җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүче затның "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль закон, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категория затларның аерым

категорияләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акчаларны һәм кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү фактларын ачыклаганда, Татарстан Республикасы Президенты контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә аңа карата башка дисциплинар җәза бирү турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка мөрәҗәгать итә.»

2. Әлеге карарны Иске Эсләк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе И.Н.Гафаров